**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы районы Ютазы
авыл җирлегенә керүче Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында
узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**«16» ноябрь 2022 ел** **№4**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 16 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегенә керүче Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылар тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә сез ризамы:

- Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 39 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 22 катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районының Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында гражданнар җыенын узган, ә нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегенә керүче Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылар тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә сез ризамы:

- Кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) - соравы буенча карарны кабул ителгән дип санарга. .

3. Халык җыенының нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга

(http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов